# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы
Петровский Завод авыл җирлегенең Петровский Завод авылы торак пунктында
2021 елда үзара салым кертү турында

**13 ноябрь 2020 ел** **№ 2**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Петровский Завод авыл җирлегенең Петровский Завод авылында гражданнар җыены

**КАРАР БИРДЕ:**

1. 2021 елда Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Петровский Завод авыл җирлеге Петровский Завод авылы территориясендә I төркем инвалидларыннан, 80 яшьтән өлкәнрәк затлардан, көндезге бүлектә укучы студентлардан тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 250 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрергә:
- Петровский Завод авылын төзекләндерү буенча эшләр өчен түләү;
- Петровский Завод авылында урамнарны яктырту лампаларын ремонтлау, сатып алу һәм алыштыру;
- Беларус -82,1 тракторын карап тоту (машина йөртүче эше өчен түләү, запас частьләр сатып алу, ягулык-майлау материаллары);
- триммерлар алу:
- Петровский Завод авылында шлагбаумнар ясау өчен төзелеш материаллары сатып алу;

Петровский Завод авылында агачлар кисү;
- мәдәни чаралар үткәрү өчен бүләкләр алу (9 май, Өлкәннәр көне, Инвалидлар көне)
- Петровский Заводы авылы зиратына вак таш җәю һәм аларның эшләре өчен түләү.

3. Әлеге карарны Петровский Завод авыл җирлеге мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә, Сарман муниципаль районының рәсми сайтында (https://sarmanovo.tatarstan.ru/), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) кабул ителгәннән соң 7 көн эчендә бастырып чыгарырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче
Сарман муниципаль районы
Петровский Завод авыл җирлеге башлыгы А. Б. Хөснетдинов